ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» сентябрь 2020 ел № 276

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе шәһәренең 8 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең штат саны турында» 2019 елның 08 маендагы 180 номерлы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы үтенечнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән өстәмә белем алуга 2014 елның 10 декабрендәге 5899 номерлы белем бирү эшчәнлегенә лицензия кушымталарына ярашлы рәвештә,
«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның ноябреннән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең «8 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең штат саны турында» 2019 елның 08 маендагы 180 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 8 нче балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең штат саны" 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Вазыйфа белән тулыландырырга:
«0,25» штат берәмлекләре саны белән «Өстәмә белем бирү педагогы»

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына, әлеге карар нигезендә, оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**